**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# 2021 елда медицина оешмасын мәҗбүри медицина иминиятләштерүгә өлкәсендә эшчәнлек алып баручы медицина оешмалары реестрына кертү турында хәбәрнамә бирү вакытын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминиятләштерүгә турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы $2^1$ өлеше нигезендә һәм Татарстан Республикасы территориясендә йогышлы яңа коронавирус чире таралу куркынычы белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Йогышлы яңа коронавирус чире белән авыруына шик туган яки расланган йогышлы яңа коронавирус диагнозы булган пациентларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары өчен 2021 елда медицина оешмасын мәҗбүри медицина иминиятләштерүгә өлкәсендә эшчәнлек алып баручы медицина оешмалары реестрына кертү турында хәбәрнамә бирү вакытын 2021 елның 1 декабренә кадәр дип билгеләргә.

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 13 ноябрь
№ ПУ-873